КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 25 апрель г.Казань № 393

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт тәрбияләү системасын булдыру буенча пилот проектын гамәлгә ашыру турында» 2021 ел, 31 март, 198 нче карары белән расланган 2021 - 2022 елларда социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган өлкән яшьтәге гражданнар һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын булдыру буенча пилот проекты чараларын финанслар белән тәэмин итү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт тәрбияләү системасын булдыру буенча пилот проектын гамәлгә ашыру турында» 2021 ел, 31 март, 198 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 9 май, 385 нче, 2021 ел, 30 декабрь, 1356 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган 2021 - 2022 елларда социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган өлкән яшьтәге гражданнар һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын булдыру буенча пилот проекты чараларын финанслар белән тәэмин итү кагыйдәләренә, 6 пунктның дүртенче абзацына «көндез тору бүлекләре эшчәнлеген оештыру өчен җиһазлар сатып алу турында» сүзләрен өстәп, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин